Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең
Ак Чишма торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
карары

29 ноябрь 2021 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021 елның «27» ноябрь 14 сәгать 00 минутта, узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сораулар буенча "Су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, смета төзү өчен түләү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкен рәсмиләштерү "гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 61 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 39 кеше, бу 64 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 39 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең Ак Чишма торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең Ак Чишма авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2022 елда 500 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: Су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, смета төзү өчен түләү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкен рәсмиләштерү

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетысында бастырырга, Ак Чишма авыл территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Л.М. Гыйниятуллина